
Бишенче апрельдә кvренекле педагогка, тарих фәннәре докторы (1963), профессор (1964), «Почет Билгесе» ордены кавалеры, тарих фәненә зур олеш керт-кән Мохәммәт Гариф улы Сәфәргалиев-ка 115 яшь тулды.
Ул 1906 елда Самара губерниясе Богелмә оязе Кузайкино волостенын кече Каратай авылында (хәзер Татарстаннын Лениногорск районы Моэмин Каратай авылы) крестьян гаиләсендә туа.

Авыр крестьян хезмәте һәм хәерчелек фән белән шогыльләнv очен вакыт та, акча да бирмәделәр. Мохәммәт 15 яшькә авыл мәктәбенен 4 сыйныфын гына тәмамлый ала. Сонрак ачлык башлана. Әти-әнисе гражданнар сугышы вакытында мәхрvм булалар һәм 1922 елда ул интернатка урнаштырыла. Тик тиздән качып китә, тиф белән авырый. 1923 елда янә Торкмәнстаннын Сыр-Дарьинск олкәсе Торкестан шәһәрендә интернатка эләгә. Анда комсомолга керә. 1924 елнын җәендә Ташкент шәһәренә педагогия техникумына укырга җибәрелә. 1929 елда укуын тәмамлаганнан сон, ул белемен дәвам итәргә карар кыла һәм Урта Азия университетынын тарих бvлегенә укырга керә. Биредә vзбәк, казакъ, торкмән, тажик, гарәп һәм фарсы телләрен мостәкыйль ойрәнә. Кичләрен, дәресләрдән сон, укыган университетында эшли, шулай ук Ташкентнын башка уку йортларында укыта. Бер vк вакытта Мохәммәт Гариф улы тикшеренv эше белән шогыльләнә, борынгы кулъязмаларны һәм китапларны ойрәнә. Университетны 1932 елда тәмамлагач, ана СССР тарихы кафедрасында калырга тәкъдим итәләр. М.Г.Сәфәргалиев оч ел дәвамында СССР халыклары тарихы буенча лекцияләр укый. 1934 елда анын vзбәк телендә беренче фәнни эше барлыкка килә. 1935 елда Мохәммәт Гариф улы Сәфәргалиев М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәv дәvләт университетынын тарих факультеты аспирантурасынын СССР тарихы кафедрасына укырга керә. Мохәммәт Гариф улы Сәфәргалиев 1939 елда «Нугай Урдасы XVI гасыр урталарында» дигән тема буенча тарих фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсе-нә диссертациясен унышлы яклый. Шулай Сәфәргалиев тарафыннан олы фәнгә юл башлана. Мәскәvнен Халык комиссариаты Мохәммәт Гариф улын Мордовия педагогия институтына СССР тарихы укытучысы итеп җибәрелә. Ә 1939 елнын февралендә, Саранскка килгәч, кафедра модире вазифаларын башкаручы итеп билгеләнә. Саранскта ул булачак хатыны, филология факультетынын икенче курс студенты, Лидия Шерстникова белән

таныша һәм ул анын тормыш юлдашы һәм ярдәмчесе була. Шул ук елны Сәфәргалиевларнын игезәк уллары - Юра белән Володя туа.
Саранскта эшләгән еллар М.Г.Сәфәр-галиев очен фәнни һәм административ эшчәнлектә аеруча унышлы була. Нәкъ биредә анын галим һәм педагог таланты тулысынча ачыла. 1939 елда тарих фәннәре кандидаты М.Г.Сәфәргалиев «Татар мәдәнияте тарихы» кулъязмасы остендә эшли башлый. Әмма уникаль китап чыгуга сугыш комачаулаган. 1941 елда институт Темников шәһә-ренә эвакуацияләнә. Мохәммәт Гариф улы сугыш елларында СССР тарих факультетын һәм тарих кафедрасын жи-тәкли. Сугыш тәмамлангач, 1940-1950 елларда vзәк һәм жирле басмаларда М.Г.Сәфәргалиевнын Алтын Урданын тарихи vткәне турында тулы эчтәлекле мәкаләләре чыга. Аннары галимнен «Алтын Урда таркалу» монографиясе китап булып донья кvрә. Идел буе халыкларынын борынгы һәм урта гасыр тарихы олкәсендәге эре белгечләре бу китапта бик кvп яна һәм кыймматле мәгълvмат туплаган дип билгеләп vткәннәр. Кулъязма остендә ул егерме ел эшләгәннән сон, 1960 елда, Мордовия дәvләт университетынын менләгән данә тиражлы галимнәр язмалары сериясендә чыгарыла. «Алтын Урданын таркалуы» монографиясе докторлык диссертациясен унышлы яклау ана 1963 елда тарих фәннәре докторы, 1964 елда профессор исемен бирv очен нигез булып тора. Әлеге монография «Фән» нәшрияты әзерләгән кvп томлы «СССР тарихы» топ хезмәтләре биографиясенә хаклы рәвештә керә.
М.Г.Сәфәргалиев эшендә булган кvп кенә материаллар һәм нәтижәләр бvгенге кондә Татарстан, Мордовия һәм Русь тарихы буенча феодализм чорындагы Россия тикшеренvчеләренен мәкаләләрендә кулланыла. «Монгол-татарлар һәм Россия халыклары» китабы доньяга чыкканнан сон да ул тема остендә эшләвен дәвам итә. Мохәммәт Гариф улынын фәнни эзләнvләрен ки-нәт кенә авыруы озә.
Профессор Сәфәргалиевнын мор-дванын феодаль монәсәбәтләр барлыкка килv проблемасын ойрәнvгә, беренче һәм февраль буржуаз-демократик революция һәм Октябрь революциясе вакытында Мордовия территориясендә барган вакыйгаларны яктыртуга керткән олеше, һичшиксез, зур.
Профессор Мохәммәт Гариф улы Сәфәргалиев Мордовия АССР Югары Советы Президиумынын Мактау грамотасы, «1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышында фидакарь хезмәт очен» медале, «Почет Билгесе» ордены белән бvләкләнгән. Әмма анын очен ин яхшы бvләк анын элеккеге студентларынын рәхмәт сvзләре булган. Элеккеге студентлары истәлекләре буенча, Мохәммәт Гариф улы гомер азагына кадәр кочле татар акценты белән сойләшкән, остәвенә, гел «шул рәвешле...» дип остәргә яраткан. Студентлары аны хормәт иткәннәр һәм яратаканнар. Ул эчтәлеге буенча тирән мәгънәле материал биргән искиткеч педагог иде.
Мохәммәт Гариф улы 1970 елнын 31 декабрендә вафат була. Хәзерге вакытта Мордовиянен А.С.Пушкин исемендәге китапханәсендә милли һәм туган як әдәбиятын ойрәнv бvлегендә Мохәммәт Гариф улы Сәфәргалиевнын тууына 115 ел тулуга багышланган «Фәнгә бирелгән тормыш» циклыннан китап кvргәзмәсе эшли. Биредә галимнен топ эше - «Алтын Урданын таркалуы» монографиясе тәкъдим ителгән. Шулай ук, кvпсанлы фәнни эшләре белән бергә, Мордовия татарлары тарихына багышланган «Мордва АССРнын татар халкы тарихы турында мәгълvмат».

**Альфия Маланьчева,**
*Мордовиянен А.С.Пушкин исемендɔге китапханɔсендɔ милли һɔм туган як ɔдɔбиятын өйрɔнv бvлеге баш китапханɔчесе*